СОВЕТ КОРГУЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАРАГУЖА АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ  КАРАР

27.07.2018  45-192

с. Коргуза

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Уставы проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль Законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы Татарстан Республикасы Законына, Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Советының 2013 нче елның 16 нчы апрелендә 32-154 нче номерлы карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегендә халык алдында тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып,

Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән Устав проектын хупларга, аны беренче укылышта кабул итергә һәм, тәкъдимнәрне, төзәтмәләрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, эшне дәвам итергә (№1 кушымта).

2. Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Уставы проекты буенча килүче тәкъдимнәрне кабул итү, исәпкә алу һәм карау буенча эшче төркем төзергә:

эшче төркем рәисе, Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы С. А. Сакин;

эшче төркем секретаре, Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре С. И. Турицина;

Эшче төркем әгъзалары:

- Пруцкова Любовь Юрьевна-Карагуҗа урта мәктәбе укытучысы
- Тюркина Галина Николаевна-Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты хисапчысы

– Кирина Алла Петровна-Карахуҗа ФАПы мөдире

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Уставы проектына карата гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга. (2 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Уставы проекты буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен расларга. (3 нче кушымта).

5. 2018 нче елның 15 нче августында Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Уставы проекты буенча ачык тыңлауларны Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авылы, Үзәк мәйдан урамы, 2 нче йорт адресы буенча уздырырга.

6. Эшче төркемгә Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегендә яшәүчеләрнең тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Советына кертергә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Бу карарның үтәлешен Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Советының социаль-мәдәни мәсьәләләр, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы С. А. Сакин